| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2025 п.г.т.Алексеевское № 601

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 23.04.2019 ел, № 167 «Алексеевск муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәтләре өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.10.2025 ел, № 03-12/7278 «Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең һәм шәһәр һәм авыл җирлекләренең бухгалтерларының хезмәтләренә түләү турында» хатын игътибарга алып

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 23.04.2019 ел, № 167 «Алексеевск муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәтләре өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МБУ, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләре бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сумнар | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Структур бүлекчә (башкарма комитет, җирле үзидарәнең башка органы бүлеге)булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение | 40700 | |

| | | |
|---|---|---|
| җитәкчесе | | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 38100 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 38100 |
| Бүлек башлыгы | 33600 | 33600 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 30600 | 30600 |
| Бухгалтер | 29000 | 29000 |

Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып структурада һәркайсында 5 берәмлектән дә ким булмаган кимендә 3 бүлек булуы тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.»

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Алексеевск муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Е.М. Мифтаховага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**